| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.02.2016 г.Казань № 11/2-пр

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасын раслау хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисади әһәмиятле төбәк программаларына теләктәшлек күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү тәртипләрен раслау турында” № 1042 карары нигезендә

боерык бирәм:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. 1 кушымтага туры китереп, Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасын;

1.2. 2 кушымтага туры китереп, 2016 елда Программаны тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибен;

1.3. 3 кушымтага туры китереп, Программаны тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү турында килешүне;

1.4. 4 кушымтага туры китереп, Программаны тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә федераль бюджет акчалары хисабыннан тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә рәвешен;

1.5. 5 кушымтага туры китереп, Программаны тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә рәвешен.

2. Тапшырыла торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларының максатчан файдаланылышы очен субсидия алучыларны, агросәнәгать комплексы оешмаларының җитәкчеләрен һәм баш бухгалтерларын җаваплы итеп билгеләргә.

3. Бюджет алучы тапшыра торган документларның дөреслеген контрольдә тоту һәм раслау буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларын җаваплы итеп билгеләргә.

4.Тармакара терлекчелекне үстерү бүлеге башлыгы С.М. Нигъмәтҗановка һәм инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы И.Ш.Гафуровка федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан, шәхси эшмәкәрләрдән документларны кабул итүне тәэмин итәргә.

5. Финанслау бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләргә субсидияләрнең үз вакытында бирелүен тәэмин итәргә.

6. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 10.02 № 11/2-пр
боерыгына 1 кушымта

# ВЕДӨМСТВОНЫҢ МАКСАТЧАН ИКЪТИСАДИ ӘҺӘМИЯТЛЕ "2016-2018 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНӘ ЧУЧКАЛАРНЫҢ АФРИКА ЧУМАСЫН КЕРТҮНЕ ҺӘМ ТАРАТУНЫ ТУКТАТУ" ТӨБӘК ПРОГРАММАСЫ

## ЭЧТӘЛЕК

1. Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасының паспорты....................3
2. Программа ярдәмендә хәл ителергә тиешле проблемаларга сыйфатлама....................5
3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары....................7
4. Максатчан индикатөрлар һәм көтелә төрган нәтиҗәләр....................7
5. Төп программа чараларының исемлеге һәм аларны сурәтләү....................9
6. Программаны тормышка ашыру вакытлары....................11
7. Программаны тормышка ашыруның соңиаль, икътисади нәтиҗәләрен сурәтләү....................11
8. Программаны үтәү куркынычларын анализлау һәм куркынычлар белән идарә итү чараларын тасвирлау....................12
9. Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм аны нигезләү.......13
10. Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары (4 таблица)....................14
11. Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү (5 таблица)....................16

**Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның аталышы | Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе территориясендә чучкаларның африка чумасы (алга таба – ЧАЧ) буенча катлаулы торган эпизоотологик вәзгыять һәм шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасына ЧАЧ таратучыны кертүгә, алга таба йогышлы чир урыннарын бетерү буенча зур икътисади югалтуларга бәйле булган зур куркынычлар.<br>2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерүнең һәм авыл хуҗалыгы продуктлары, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.07.2012 № 717 карары белән расланды), “2-13-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продуктлары, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 08.04.2013 № 235 карары белән расланды). |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы территориясен һәм чучкачылык оешмаларын ЧАЧ кертүдән һәм таратудан яклау |
| Программада катнашучылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, милекчелекнең барлык рәвешләрендәге чучкачылык оешмалары. |
| Программаның төп чаралары | Чучкачылык оешмаларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча объектлар әзерләү<br>Йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чарлар сатып алу.<br>Эшче персонал очен һәм чучкачылык оешмаларындагы хезмәткәрләр өчен махсус кием-салым сатып алу.<br>Йогышсызлый торган җайланма сатып алу.<br>Татарстан Республикасы чиген үтә торган транспорт |

<table>
<tr><td></td><td>чараларын караунын уртак постларын оештыру һәм аларны эшләтү.<br>Чучкачылык оешмаларында, шәхси ярдәмче һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларында, шәхси эшмәкәрләрне һәм кыргый фаунаны да кертеп, ЧАЧ буенча мониторниглауны тәэмин итү.<br>ЧАЧ кисәтүне оештыру мәсьәләләрендә ветеринария белгечләренең квалификациясен үстерү.</td></tr>
<tr><td>Программаны үтәү вакытлары һәм этаплары</td><td>2016-2018 еллар</td></tr>
<tr><td>Программаны башкаручылар</td><td>Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, милекчелекнең барлык рәвешләрендәге чучкачылык оешмалары</td></tr>
<tr><td>Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td>2016-2018 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме 650,0 миллион сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан;<br>- бюджетныкы булмаган чыганаклар – 611,0 миллион сум.<br>Программаның үтәлешен еллар буенча ресурслар белән тәэмин итү күләме:
<table>
<tr><td rowspan="2">Еллар</td><td colspan="3">Акча күләме, миллион сум</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>Бюджетныкы булмаган чыганаклардан</td><td>Барлыгы</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>12</td><td>188</td><td>200</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>13</td><td>202</td><td>215</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>14</td><td>221</td><td>235</td></tr>
<tr><td>Җәмгысе:</td><td>39</td><td>611</td><td>650</td></tr>
</table></td></tr>
<tr><td>Программаның максатларын үтәү буенча көтелә торган нәтиҗәләр һәм Программаның бурычлары</td><td>Программаны тормышка ашыру 2018 елга түбәндәгеләрне мөмкин итәчәк:<br>чучкачылык оешмаларын биологик иминлек объектлары белән тәэмин итү һәм аларның техник торышын карап тоту – 2015 ел дәрәҗәсенә карата кимендә 90%;<br>планлы ветеринария-санитария чараларын башкару (йогышсызландыру, дератизацияләү, дезинсекцияләү) – 2015 ел дәрәҗәсенә карата кимендә 100%;<br>чучкачылык оешмаларында эшләүчеләрне һәм белгечләрне махсус кием-салым белән тәэмин итү – 92% тәэмин ителеш;<br>йогышсызландыра торган җайланма сатып алу – 27</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | берәмлек;<br>өстәмә эш урыннары булдыру - 36 кеше;<br>ЧАЧ буенча хәерсез пунктларны теркәү, саннарда – 0;<br>ЧАЧ буенча тикшерүләр белән чучкаларның баш саныннан үткәрелгән тикшерүләрнең саны 0,5 процент дәрәҗәсендә бирешүчән хайваннарны камап алу;<br>квалификациясен үстергән ветеринария белгечләренең санын тәэмин итү, саннарда – 51 берәмлек. |
| Контрольлек идарә системасы | Программаны үтәү буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы булып тора. |

## 1. Программа ярдәмендә хәл итәлә торган проблемаларга сыйфатлама

ЧАЧ аеруча куркыныч булган йогышлы чир төркеменә карый, йорт чучкаларына, кыргый чучкаларга йога һәм, ни рәвешле таралуына карамастан, төрле яшьтәге хайваннарның 100% үлеменә китерә. Әлеге чирне әйләнә-тирә мохиткә югары дәрәҗәдә чыдам булган вирус китереп чыгара. ЧАЧ кисәтү һәм дәвалау буенча безнең илдә һәм чит илдә ветеринария олкәләрендә махсус чаралар эшләнмәгән.

Россия Федерациясе территориясендә ЧАЧ белән чучкаларның авырып китүенә бәйле вәзгыять киеренке булып кала.

2007 елдан башлап 2016 елның 1 февраленә кадәрге чорда Россия Федерациясендәге 37 субъектта әлеге чирнең 807 очрагы теркәлде, алардан: 409 – йорт чучкалары арасында, 366 – кыргый чучкалар һәм йогышланган 32 объект.

2007 елдан башлап хәзергәчә, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы бәяләмәсе буенча, Россиянең агросәнәгать комплексына ЧАЧ китергән турыдан-туры зыянның күләме 30 миллиард сумнан артып китте.

2015 елда Россия Федерациясенең түбәндәге 14 субъектында әлеге чир барлыкка килүнең 84 очрагы теркәлде: Брянск, Волгоград, Калуга, Курск, Мәскәү, Орлов, Псков, Саратов, Владимир, Смоленск һәм Ярославль өлкәләрендә, Краснодар краенда һәм Кабарда-Балкар Республикасында. Алардан: йорт чучкалары арасында – 45, кабаннар арасында – 39.

2015-2016 елларда, шул исәптән Татарстан Республикасына якын урнашкан чикләрдә әлеге чирнең барлыкка килүе аеруча борчый. 2015 ел очен Саратов өлкәсендә 11 чир очрагы ачыкланды, шул исәптән: 6 – йорт чучкалары һәм 5 – кабаннар арасында. Пенза өлкәсендә, Россиянең Пенза өлкәсе буенча ИК-8 УФСИН ФКУ булган ярдәмче хуҗалык территориясендә (Пенза ш.) 2016 елның 25 гыйнварында ЧАЧ теркәлде.

ЧАЧ вирусын тапшыру факторлары төрле-торле: тере һәм һәлак булган йогышлы терлекләр, йогышлы чучкаларны чалудан алынган продуктлар,

тирес, терлек азыгы, инвентарь, транспорт, бөҗәкләр һәм кимерүчеләр. Кыргый чучкалар вирусны яшерен йөртүчеләр булып санала һәм билгеле бер шартларда йорт чучкаларын зарарлый алалар.

Татарстан Республикасында чучкачылык тармагы югары тизлектә үсә. Чучка җитештерү һәм сату хокук буенча Россия Федерациясендә лидерлык урынын алып тора.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясе ЧАЧтан азат. Ләкин әлеге чирне хәерсез төбәкләрдән кертү куркынычы бар һәм аны юкка чыгару нәтиҗәләре зур-зур икътисади югалтуларга китерәчәк.

Тобәктә ЧАЧ барлыкка килү – барлык чучкачылык тармагы өчен катастрофа булып тора, түбәндәге сәбәпләр аркасында:

чир барлыкка килгән урыннарда терлекләр һәлак булуның югары дәрәҗәсе;

куркыныч белән яный торган зоналарда чучкаларның популяцияләре тоталь рәвештә юкка чыгуы;

авыл хуҗалыгы продуктларын экспортлауны тулысынча тыю һәм чучкачылык чималын һәм продуктларын төбәк чикләреннән тыш сатуга чикләмәләр кертү;

йогышлы чирне юкка чыгару, контрольдә тоту һәм тотып тору өчен зур финанс акчаларын бүлеп бирү зарурлыгы.

Төбәкләргә ЧАЧ вирусын кертүнең турыдан-туры юллары булып түбәндәгеләр тора: тикшерелми торган рәвештә терлек ташу, термик яктан эшкәртелмәгән терлек азыгы, шулай ук чучка җитештерү буенча эре оешмалар тарафыннан “ябык типтагы” тәртип сакланмау.

Республика икътисадын тотрыклы үстерү һәм ЧАЧ вирусын Татарстан Республикасы территориясенә кертүне туктатуга юнәлдерелгән чаралар комплексын башкару өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру буенча мәсьәлә калку тора:

барлык чучкачылык оешмаларын да “ябык тип”ка күчерү һәм шәхси секторда чучкаларны урамга чыгармыйча асрауны тәэмин итү;

чучкачылык хуҗалыкларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча эшләр оештыру һәм республика территориясендә чучкаларның баш санын исәпкә алуны тәэмин итү;

Татарстан Республикасының автомобиль юлларында, ветеринария буенча теркәлә торган документлардан башка хәрәкәт итүче терлекчелек йөкләрен һәм ЧАЧ буенча хәерсез төбәкләрдән килүче йөкләрне туктату максаты белән, автотранспортны тикшерү һәм карау;

йогышсызландыра торган, акарицидлы чараларны һәм дератизацияләү өчен чараларның һәм терлекләрне кан чыкмый торган итеп чалу чараларының запасын, йогышлы чир урыннарында эшләү өчен махсус кием-салым (шәхси саклык чаралары) запасларын булдыру;

Татарстан Республикасындагы чучкачылык хуҗалыкларында, Татарстан Республикасы территориясендә ЧАЧ кертүне һәм таратуны туктату буенча чаралар үтәлешенә карата, даими контроль тикшерүләр үткәреп тору.

Шул рәвешле, Программаны үтәү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекләре булып түбәндәгеләр тора: ЧАЧ вирусын Татарстан Республикасы территориясенә кертне булдырмый калу, тотрыклы эпизоотик вәзгыятьне саклау, чучкачылык тармагын сәнәгый нигездә үстерү.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты – Татарстан Республикасы территориясен ЧАЧ кертүдән һәм таратудан саклау. Аталган максатка ирешү очен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк:

чучкачылык хуҗалыкларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча эшләр оештыру;

республика территориясен чирне аның чикләреннән кертүгә карата саклау;

ЧАЧ карата эпизоотик мониторинглауны оештыру һәм аны башкару;

ЧАЧ кисәтү методларын камилләтерү һәм чир йоктыручыларны республика территориясенә кертүдә мөмкин булган юлларны өйрәнү.

1 таблица.

Баш саны 2,0 меңнән артык булган чучкачылык хуҗалыклары исемлеге.

| № п/п | Субсидия алучының чучкачылык оешмасы аталышы | Чучкалар саны, мең баш |
|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе районының “Ак-Барс Әгерҗе” АФ ҖЧҖ | 6.4 |
| 2 | Актаныш районының “Нур Баян ис.” ҖЧҖ | 3,6 |
| 3 | Әлки районының “Салман” ҖЧК ҖЧҖ | 9,8 |
| 4 | Балтач районының Яңа тормыш ҖЧҖ | 2,8 |
| 5 | Балтач районының “Кама” АХҖК | 2,1 |
| 6 | Балтач районының “Татарстан” АХП ҖЧҖ | 2,5 |
| 7 | Балтач районының “Хезмәт” ҖЧҖ | 2,6 |
| 8 | Буа районы репродукторы - “Авангард” ҖЧҖ | 25,6 |
| 9 | Югары Ослан районының “Пашков С.И.” КФХ | 4,8 |
| 10 | Яшел Үзән районының “Авангард” ЯАҖ | 2,2 |
| 11 | Кукмара районының “Тойма” ҖЧҖ | 2,1 |
| 12 | Лениногорск районының “Ялтау” АФ ҖЧҖ | 16,8 |
| 13 | Түбән Кама районының “Нефтехимагропром” ҖЧҖ | 11,0 |
| 14 | Түбән Кама районының “Союз-Агро” а/х ҖЧҖ | 7,2 |
| 15 | Балык Бистәсе районының “Агрокам” ҖЧҖ | 2,4 |
| 16 | Саба районының “ТАТМитАгро” ҖЧҖ | 39,6 |
| 17 | Тукай районының “Камский бекон” ҖЧҖ | 223,6 |
| 18 | Кукмара районының “Вахитов” ҖЧҖ | 2,0 |
|  | Җәмгысе: | 367,2 |

## III. Максатчан индикаторлар һәм көтелә торган нәтиҗәләр

Программаның үтәлеш нәтиҗәсе сан күрсәткечләреннән чыгып билгеләнә, алар объективлык, дөреслек, үтәкүренмәлелек, чагыштыручанлык критерийларына җавап бирергә тиеш.

Программаның максатчан индикаторлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

биологик иминлек объектлары белән тәэмин ителгәнлек һәм аларның техник торышы;

планлы ветеринария-санитария чараларын (йогышсызландыру, дератизацияләү, дезинсекцияләү) башкару;

чучкачылык оешмаларында эшләүчеләрне һәм хезмәткәрләрне махсус кием-салым белән тәэмин итү;

йогышсызландыра торган җайланма сатып алу;

өстәмә эш урыннары булдыру;

ЧАЧ буенча хәерсез пунктларның саны;

ЧАЧ карата бирешүчән хайваннарны тикшерүләр белән камау;

квалификациясен үстергән ветеринария белгечләренең саны.

Төп чаралар кисемендә Программаның максатлары, бурычлары, аның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары 2 һәм 4 таблицада китерелде.

Программаны үтәү 2018 елга түбәндәгеләрне мөмкин итәчәк:

чучкачылык оешмаларын биологик иминлек объектлары белән тәэмин итү һәм аларның техник торышын карап тоту – 2015 ел дәрәҗәсенә карата кимендә 90%;

планлы ветеринария-санитария чараларын башкару йогышсызландыру, дератизацияләү, дезинсекцияләү) – 2015 ел дәрәҗәсенә карата кимендә 100%;

чучкачылык оешмаларында эшләүчеләрне һәм белгечләрне махсус кием-салым белән тәэмин итү – 92% тәэмин ителеш;

йогышсызландыра торган җайланма сатып алу – 27 берәмлек;

өстәмә эш урыннары булдыру - 36 кеше;

ЧАЧ буенча хәерсез пунктларны теркәү, саннарда – 0;

ЧАЧ буенча тикшерүләр белән чучкаларның баш санынннан үткәрелгән тикшерүләрнең саны 0,5 процент дәрәҗәсендә бирешүчән хайваннарны камап алу;

квалификациясен үстергән ветеринария белгечләренең санын тәэмин итү, саннарда – 51 берәмлек.

2 таблица

Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары

| Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2015 (база) ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
| Чучкачылык оешмаларын биологик иминлек объектлары белән тәэмин итү һәм | 75% | 80% | 85% | 90% |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| аларның техник торышын карап тоту – 2015 ел дәрәҗәсенә карата | | | | |
| Планлы ветеринария-санитария чараларын башкару йогышсызландыру, дератизацияләү, дезинсекцияләү) – 2015 ел дәрәҗәсенә карата | 100% | 101% | 102% | 103 % |
| Чучкачылык оешмаларында эшләүчеләрне һәм белгечләрне махсус кием-салым белән тәэмин итү | 80% | 84% | 88% | 92% |
| Йогышсызландыра торган җайланма сатып алу, берәмлек | 2 | 8 | 9 | 10 |
| Өстәмә эш урыннары булдыру, кеше саны | - | 12 | 12 | 12 |
| ЧАЧ буенча хәерсез пунктларны теркәү, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 |
| ЧАЧ буенча тикшерүләр белән бирешүчән хайваннарны камап алу, чучкаларның баш санынннан үткәрелгән тикшерүләрнең саны | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 |
| Квалификациясен үстергән ветеринария белгечләренең саны, кеше | 15 | 17 | 17 | 17 |

## IV. Төп программа чараларының исемлеге һәм аларны сурәтләү

Куелган мәсьәләне үтәү Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең, Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (алга таба – Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсе), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең, милекчелекнең барлык рәвешләрендәге чучкачылык оешмаларының координацияле уртак гамә кылуын күздә тота.

Чараларны тормышка ашыру ЧАЧ вирусын республика территориясенә кертүне туктатуда кызыксынган структура һәм ведомстволарның тулысынча уртак хезмәттәшлек итүен мөмкин итәчәк, кисәтү чараларын үткәрүнең тизлеген арттырачак, чирне диагностикалау мәсьәләләрендә лаборатория тәҗрибәсен камилләштерергә, ветеринария белгечләренең һөнәри әзерлеген яхшыртырга булышачак.

Программаны үтәү өчен түбәндәге ресурслар сорала:

- оештыру – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор

идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы көчләре белән оештырылган чараларны үткәрү;

- техник – автотранспорт, йогышсызлый торган техника, заманча лаборатория җайланмасы, оргтехника һәм бүтән торле матди-техник чаралар һәм җайланмалар;

- кадрлар – Программаны башкаручылар оештыру мәсьәләләрен хәл итүне, фәнни-методологик тәэминат эшләүне һәм кертүне тәэмин итәләр.

Программа Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең, Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсенең, Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең, Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм шәһәр җирлекләре хакимиятләренең кадрлар потенциалыннан файдалануны күздә тота.

Программаны үтәү механизмы югарыда билгеләп үтелгән стратегик бурычларга туры килә һәм түбәндәге юнәлешләр буенча башкарыла:

**1. Татарстан Республикасы территориясенә ЧАЧ кертмәү.**

Дәүләт ветеринария хезмәте контрольлегендә булган йөк ташуларны ветеренария буенча теркәү документларыннан башка яки аларның ветеринария таләпләрен бозып бирелүен булдырмау.

Хуҗалык итүче субъектларның контрольлектә булган йөкләрне төбәк чикләреннән кертүне (чыгаруны) дәүләт ветеринария хезмәте белән килештерүе.

Республика территориясендә кыргый кабаннарның санын мөмкин кадәр киметү һәм кыргый фаунада миграцияләүче хайваннарның активлыгын анализлау.

Татарстан Республикасындагы чучкачылык оешмаларында, шәхси ярдәмче һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларында, кыргый фаунада һәм ит продуктларында расланган мониторинг тикшеренүләре кысаларында ЧАЧ буенча мониторинглауны тәэмин итү.

ЧАЧ вирусын лабораториядә диагностикалау буенча прогрессив методларны кертү.

Республикадагы ветеринария белгечләренең ЧАЧ кисәтүне оештыру мәсьәләләрендә, ЧАЧ диагностикалаучы лаборатория белгечләренең квалификациясен үстерү һәм аларны аттестацияләү.

Ветеринария хезмәтләре, аучылык хуҗалыклары, авыл җирлекләрендәге хакимиятләрнең, Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының һәм барлык кызыксынган хезмәтләрнең һәм ведомстволарның вәкилләре катнашында белем бирә торган семинарлар (укулар) үткәрү.

Татарстан Республикасының күрше төбәкләре белән чирне кисәтү буенча үткәрелә торган чаралар, аны тарату мөмкинлеге булган юллар турында мәгълүмат белән алмашу.

**2. Тотрыклы эпизоотик вәзгыятьне саклау.**

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе һәм Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсе органнары арасында уртак хезмәттәшлек итүне оештыру.

Татарстан Республикасы чикләрен үтеп чыга торган транспорт чараларын карау һәм аларга карата ветеринария-санитария эшкәртүләрен үткәрү буенча уртак постларны оештыру һәм аларны эшләтү.

Барлык җитештерү стадияләрендә дә биологик калдыкларны җыеп алу һәм утильләштерү буенча контрольлек-күзәтчелек чараларын катгыйландыру.

Муниципаль районнар һәм шәһәрләр территорияләрендә дәүләт ветеринария хезмәтенең эпизоотикага каршы мобиль отрядларының тулы әзерлектә булуын тәэмин итү (матди-техник, йогышсызландыра тора чараларның, махсус кием-салымның, шәхси саклык чараларының булуы).

Ит продуктларын санкцияләнмәгән урыннарда сатуга юл куймау буенча эшләрне көчәйтү.

Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең ярдәмче хуҗалыкларында, чучкачылык оешмаларында, эшмәкәрләрнең хуҗалыкларында, крестьян (фермер), шәхси ярдәмче, гражданнарның хуҗалыкларында азык-төлек калдыклары һәм ашханәдән калган азык-төлек калдыклары белән, аларны АЧС вирусын уятучыны юкка чыгаруга карата термик эшкәртмичә, ашатуга юл куймау.

Терлекне исәпкә алуның электрон системасын кертү һәм республика территориясендә терлекләр саны реестрын алып бару.

**3. Чучкачылык тармагын сәнәгый нигездә үстерү.**

Эре чучкачылык холдингларында итне тулысынча сәнәгый эшкәртә торган, аның ирекле сәүдәгә эләгү мөмкинлеген юкка чыгара торган технологияләр белән санитар сугым урыннары төзү.

Чучкачылык оешмаларының “ябык типтагы” тәртиптә эшләрен контрольдә тоту, шулай ук ЧАЧ булдырмауга бәйле рәвештә, күзәтчелек чараларын үткәрү.

ЧАЧ йоктыручы факторларны юкка чыгара торган термик эшмәртмичә торып, чучкачылык тармагы өчен терлек азыгы әзерләнүгә юл куймау.

Программа чараларын тормышка ашыруны контрольдә тоту билгеләнгән тәртиптә, гамәлдә булган хисапнамә системасы кысаларында җыеп алына торган, Программаны үтәү барышы турындагы мәгълүмат базасында гамәлгә ашырыла.

Программаны үтәү белән идарә итү һәм аны контрольдә тоту түбәндәге бурычларны үз эченә ала:

Программаны үтәү буенча эшләрнең башкарылу планын эшләү;

алынган күрсәткечләр нигезендә Программа үтәлешен мониторинглау;

Программаны үтәгәндә барлыкка килә торган тайпылышлар белән идарә итү;

Программаның үтәлеш этапларын теркәү буенча агымдагы идарәлек.

## V. Программаны үтәү вакытлары

Программаны үтәү вакытлары: 2016-2018 еллар.

## VI. Программаны үтәүнең социаль, икътисади нәтиҗәләрен тасвирлау

Программаның эшләмәү очракларында яки финанслау күләме планлаштырганга караганда кимрәк дәрәҗәдә булганда ЧАЧ куркынычына бәйле вәзгыять контрольдән чыгарга момкин, чучкаларның африка чумасы киң таралудан барлыкка килгән нәтиҗәләрнең күләме безнең республикадагы чучкачылык һәм азык-төлек иминлеге тармагы өчен күп очракта шушы Программада каралган чараларны тормышка ашыру өчен тотылган чыгымнарны күпләтә арттырачак.

“Россия авыл хуҗалыгы фәннәр академиясенең ветеринария вирусологиясе һәм микробиологиясе Россиякүләм фәнни-тикшеренү институты” дәүләт фәнни учреждениесе галимнәре исәпләп чыгарганча, 2011 елда чучкаларның африка чумасы буенча бер хәерсез пунктны юкка чыгару өчен турыдан-туры һәм читләтеп торкан чыгымнар күләме 37 миллион сумнан артык тәшкил иткән.

Республика территориясенә ЧАЧ йоктыручыны кертүдән туктату буенча чараларны тормышка ашыру түбәндәгеләрне мөмкин итәчәк:

чучкачылык тармагының тотрыклы эшләвен;

чирне юкка чыгару өчен сарыфларга юл куелмауны;

Россия Федерациясенең барлык территориясендә чучкачылык продуктларын ирекле сатуны һәм экспортка куюны тәэмин итүне.

Программаның аралык һәм төгәлли торган бәяләмәсе Татарстан Республикасы территориясенә ЧАЧ кертүне булдырмау сәләтенә нигезләнә.

## VII. Программаны тормышка ашыру куркынычларын анализлау һәм куркынычлар белән идарә итү чараларын сурәтләү

Максатка ирешү өчен аларның йогынтысын киметү максатында куркынычлар белән идарә итү компоненты Программаны уңышлы тормышка ашыруның әһәмиятле шарты булып тора.

2007 елдан башлап хәзерге вакытка кадәр ЧАЧ очракларын юкка чыгарганда 1 миллионнан артык чучка юкка чыгарылды һәм читләштерелде. Бүгенге көндә чучкаларның шушы чиреннән турыдан-туры һәм читләтеп тотылган сарыфлар 30 миллиард сумнан артып китте. Кайбер төбәкләрдә чума фактта чучкачылыкның терлекчелек тармагы буларак юкка чыгуына

китерде. Берничә эре чучкачылык комплекслары дистәләрчә мең чучканы утильләштерергә, яндырырга мәҗбүр булды.

Татарстан Республикасына ЧАЧ кертүнең югары мөмкинлеген түбәндәгеләр билгели:

географик урнашу урыны, башка субъектлар белән киң күләмле сәүдә-хуҗалык элемтәләре, транспорт агымының югары концентрациясе;

йорт чучкаларының һәм кыргый кабаннарның бирешүчән популяцияләренең күпсанлы булуы;

чучкачылык оешмаларының, шулай ук шәхси ярдәмче һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларының беркадәр өлеше ЧАЧ вирусыннан тиешле дәрәҗәдә якланмаган булуы;

шәхси ярдәмче хуҗалыкларда һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларында чучкаларны тоту буенча үтәү өчен мәҗбүри кагыйдәләрнең булмавы;

республика территориясенә терлекчелек продуктларын һәм терлекләрне санкцияләнмәгән рәвештә кертү очраклары;

ЧАЧ диагностикалау лабораторияләре белән кирәкле күләмдә тәэмин ителмәгәнлек, тиешле техник чараларның яңартылмавы, мөмкин булган йогышлы чир урыннарын юкка чыгару буенча матди һәм кеше ресурсларының әзерлексез булуы, йогышлы чирне кертү очрагында кирәкле чараларны оештырмау һәм алар белән тәэмин ителмәү.

Шул рәвешле, Программаны тормышка ашыруда тышкы һәм эчке куркынычлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт булырга мөмкин:

Россия Федерациясендә һәм сәүдә партнерлары булган илләрдә йогышлы, шул исәптән аеруча куркыныч терлек чирләре буенча эпизоотик вәзгыятьнең начарлануы;

республика территориясендә техноген һәм табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

Татарстан Республикасындагы дәүләт бюджет учреждениеләренең чараларны үткәрү өчен кирәкле булган чаралар белән тиешле дәрәҗәдә тәэмин ителмәве;

кадрлар кытлыгы һәм дәүләт бюджет ветеринария учреждениеләрендәге хезмәткәрләрнең квалификациясе тиешле дәрәҗәдә булмау;

икътисади вәзгыять аркасында, бюджетны формалаштырганда чыгымнарны оптимальләштерү нәтиҗәсендә Программа чараларын тормышка ашыруга юнәлтелә торган республика бюджеты акчаларының күләме кимү.

Тышкы һәм эчке факторларның гамәлләре белән аңлатыла торган куркынычларны киметү Программаны җаваплы башкаручы тарафыннан, терлекләрнең йогышлы чирләре барлыкка килүне кисәтү, Татарстан Республикасының бюджет ветеринария учреждениеләренә дәүләт ярдәме чараларын көчәйтү максатларында, федераль башкарма хакимият органнарына һәм Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органнарына ветеринария өлкәсендәге федераль законнарны һәм төбәк

законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнамәләр рәвешендә тиешле инициативалар тәэмин ителә.

Аталган куркынычларны чикләү максатларында дәүләт Программасы чараларын үтәү барышын даими тикшереп торуны оештыру зарур, алынган мәгълүматларны гомумиләштереп анализлау, аталган чараларга үз вакытында төзәтмәләр кертергә, куелган мәсьәләләрнең үтәлү динамикасына һәм тизлегенә карап, финанслау күләмнәрен яңадан бүләргә кирәк, бу исә, тулаем алганда, куелган максатларга ирешүне мөмкин итәчәк.

## VIII. Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм аны нигезләү

2016-2018 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме 650 миллион сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан – 39,0 миллион сум;
- бюджетныкы булмаган чыганаклар – 611,0 миллион сум.

3 таблица

Программаны үтәү өчен елларша бүленгән ресурслар белән тәэмин ителеш күләме:

| Еллар | Акча күләме, миллион сум | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | Бюджетныкы булмаган чыганаклар | БАРЛЫГЫ |
| 2016 | 12 | 188 | 200 |
| 2017 | 13 | 202 | 215 |
| 2018 | 14 | 221 | 235 |
| Барлыгы | 39 | 611 | 650 |

Программа юнәлешләре буенча Татарстан Республикасы бюджеттыннан бүлеп бирелә торган акчаларның суммасы ел саен Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законы нигезендә чираттагы финанс елына һәм планлы чорга карата тәгаенләнәчәк.

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларныц африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасын тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү 5 таблицада күрсәтелде.

Программага карата
4 таблица

**Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

| Бурычның аталышы | Төп чараларның аталышы | Башкаручылар | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2015 (база) ел | 2016 | 2017 | 2018 |
| Чучкачылык оешмаларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча эшләрне оештыру | Чучкачылык оешмаларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча объектларны әзерләү | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | Биологик иминлек объектлары белән тәэмин ителгән һәм аларның техник торышы, 2015 ел дәрәҗәсенә карата процентларда | 75% | 80% | 85% | 90% |
| | Йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чаралар сатып алу | | Планлаштырылган ветеринария-санитария чараларын башкару (йогышсызландыру, дератизацияләү, дизенсекцияләү), 2015 ел дәрәҗәсенә карата процентларда | 100% | 101% | 102% | 103% |
| | Чучкачылык оешмаларында эшләүчеләр һәм белгечләр өчен махсус кием-салым сатып алу | | Чучкачылык оешмаларында эшләүчеләрне һәм хезмәткәрләрне махсус кием-салым белән тәэмин итү, тәэмин ителеш проценты | 80% | 84% | 88% | 92% |
| | Йогышсызлый торган җайланма сатып алу | | Йогышсызлый торган җайланма сатып алу, берәмлек | 2 | 8 | 9 | 10 |
| | Өстәмә эш урыннары булдыру | | Өстәмә эш урыннары булдыру, кеше саны | - | 12 | 12 | 12 |
| Республика территориясен аның | Татарстан Республикасы чикләрен үтеп чыга торган транспорт чараларын карау һәм тикшерү буенча уртак | | ЧАЧ буенча хәерсез пунктларны теркәү, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| чикләренн ән чир кертүдән саклау | постлар оештыру һәм аларны эшләтү | | | | | | |
| ЧАЧ эпизоотик мониторин глауны оештыру һәм башкару | Чучкачылык оешмаларында, шәхси ярдәмче һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларында, шәхси эшмәкәрләрне һәм кыргый фаунаны да исәпкә алып, ЧАЧ буенча мониторинг оештыру | | ЧАЧ буенча бирешүчән терлекләрне тикшерүләр белән камау, чучкаларның баш санына карап, үткәрелгән тикшерүләрнең сан проценты | 0,5 | 0,5 | 0,5 | 0,5 |
| ЧАЧ кисәтү методларын камилләштерү һәм чир йоктыруның мөмкин булган юлларын өйрәнү | ЧАЧ кисәтүне оештыру мәсьәләләрендә ветеринария белгечләренең квалификациясен үстерү | | Квалификацияләрен үстергән ветеринария белгечләренең саны, кеше | 15 | 17 | 17 | 17 |

5 таблица.

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасын кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасы үтәлешен ресурслар белән тәэмин итү (миллион сум)

| Бурычның аталышы | Чараның аталышы | Финанс чыганагы | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Программа буенча җәмгысе | | Барлыгы: | 200,0 | 215,0 | 235,0 |
| | | Татарстан Республикасы | 12,0 | 13,0 | 14,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | бюджеты | | | |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | 188,0 | 202,0 | 221,0 |
| Чучкачылык оешмаларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча чаралар оештыру | Чучкачылык оешмаларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча объектлар әзерләү | Барлыгы: | 50,0 | 53,8 | 58,8 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 3,0 | 3,3 | 3,5 |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | 47,0 | 50,5 | 55,3 |
| | Йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чаралар сатып алу | Барлыгы: | 90,0 | 96,8 | 105,8 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 5,4 | 5,9 | 6,3 |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | 84,6 | 90,9 | 99,5 |
| | Чучкачылык оешмаларында эшләүчеләр һәм белгечләр өчен махсус кием-салым сатып алу | Барлыгы: | 30,0 | 32,3 | 35,3 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 1,8 | 2,0 | 2,1 |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | 28,2 | 30,3 | 33,2 |
| | Йогышсызландыра торган җайланма сатып алу | Барлыгы: | 30,0 | 32,3 | 35.3 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 1,8 | 2,0 | 2,1 |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | 28,2 | 30,3 | 33,2 |
| **Моннан тыш:** | | | | | |
| Республика территориясен аның чикләреннән йогышлы чир кертүдән саклау | Татарстан Республикасы чикләрен үтеп чыга торган транспорт чараларын карау һәм тикшерү буенча уртак постлар оештыру һәм аларны эшләтү | Барлыгы: | 0,5 | 0,6 | 0,7 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 0,5 | 0,6 | 0,7 |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | - | - | - |
| ЧАЧ эпизоотик мониторинглауны оештыру һәм башкару | Чучкачылык оешмаларында, шәхси ярдәмче һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларында, шәхси эшмәкәрләрне һәм кыргый фауналы да исәпкә алып, ЧАЧ буенча мониторинг оештыру | Барлыгы: | 0,14 | 0,12 | 0,25 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | 0,1 | 0,150 | 0,2 |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | 0,04 | 0,05 | 0,05 |
| ЧАЧ кисәтү методларын камилләштерү һәм чир йоктыруның | ЧАЧ кисәтүне оештыру мәсьәләләрендә ветеринария белгечләренең квалификациясен үстерү | Барлыгы: | 0,06 | 0,06 | 0,06 |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | - | - | - |
| | | Бюджетныкы булмаган чыганак | 0,06 | 0,06 | 0,06 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| мөмкин булган юлларын өйрәнү | | | | | |

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 10. 02. № 11/2-и
боерыгына 2 кушымта

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасында катанашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2016 елда субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (алга таба – Программада катнашучылар) субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр “2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында” Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) шушы Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.

3. Программада катаншучының милегендә һәм (яки) аренда шартларында чучкалар булу субсидияләр бирелүнең шарты булып тора.

4. Арбитраж суды тарафыннан Программада катнашучыга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта, алар (катнашучылар) бу хакта эш кузгатылган көнне Министрлыкка язмача хәбәр итәргә бурычлы. Арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган Программада катнашучыларга субсидияләр бирелми.

5. Татарстан Республикасы территориясен чучкаларның африка чумасын кертүдән һәм таратудан яклау субсидия бирүнең максаты булып тора;

а) объектларны чучкачылык хуҗалыкларының биологик иминлеген тәэмин итү өчен әзерләүдә тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, - Программаны үти башлаганнан соң бер елдан да иртәрәк булмаган чорда башкарылган эшләр күләменнән 23 проценты күләмендә, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 17 процент;

б) йогышсызландыра торган, акариңидлы, дератизацияли торган чаралар, йогышсызландыра торган җайланма, чучкачылык предприятиеләрендә эшләүчеләр һәм белгечләр өчен махсус кием-салым сатып алу буенча тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга, - Программаны үти башлаганнан соң бер елдан да иртәрәк булмаган чорда сатып алынган йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чараларның, йогышсызландыра торган җайланманың, эшче персонал өчен

алынган кием-салымның гомуми бәясенең 23 проценты күләмендә, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 17 процент.

7. Шушы Тәртипнең 6 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

объектны чучкачылык хуҗалыгының биологик иминлеген тәэмин итү буенча әзерләүгә карата җыелма смета исәпләмәсенең күчермәсе;

объектны чучкачылык хуҗалыгының биологик иминлеген тәэмин итү буенча әзерләүгә подряд шартнамәсенең күчермәсе;

№КС-2 “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” статистика рәвешләре буенча белешмә;

№КС-3 “Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмә” статистика рәвеше буенча белешмә;

№КС-2 “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” һәм №КС-3 “Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмә” статистика рәвешләре буенча белешмәләр, - эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда;

башкарылган эшләр өчен түләгәнлекне раслый торган, банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәсе;

Министрлык тарафыннан расланган рәвештә субсидияләрне бирү өчен белешмә-исәпләмәләр.

Тапшырылган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

9. Министрлык:

субсидияләр бирелү турында гаризаны кергән көненнән соң бер көн эчендә терки;

гаризаны теркәгәннән соң 20 көнлек чорда тапшырылган документларны шушы Тәртипнең 7 һәм 8 пунктлары нигезендә тикшерә һәм субсидияне бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Субсидияләр бюджет акчалары кысаларында гаризалар тапшырылу тәртибендә бирелә.

Субсидияне бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның шушы Тәртип таләпләренә җавап бирмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык 9 пунктның өченче кызыл юлында күрсәтелгән чор узганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.

Субсидия бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

11. Министрлык Программада катнашучылар белән Министрлык тарафыннан раслана торган рәвештә Субсидияләр бирелү турында килешү

(алга таба – Килешү) төзи, анда субсидия алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләрне алучылар тарафыннан аларны бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүен тикшерүгә ризалык бирүе субсидия бирелүнең мәҗбүри шарты булып тора.

12. Министрлык бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментында ачылган лицевой счетларыннан Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына, субсидияләрне бирү өчен Министрлык тарафыннан расланган белешмә-исәпләмәләр нигезендә, шушы Тәртипнең 9 пунктындагы өченче кызыл юлда күрсәтелгән вакыт узганнан соң ункөнлек чорда акча чараларын күчерә.

13. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемена кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемена кире кайтарылырга тиеш.

15. Бу Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет керемена ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

16. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

17. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазифаи затларына йөкләнә.

18. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 10. 02. № 11/2-пр
боерыгына 3 кушымта

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның
африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” тобәк программасын
тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар
җитештерүчеләренә субсидияләр бирелү турында
КИЛЕШҮ №_______

Казан ш. “_____”_______________2016

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-толек министрлыгы, алга таба “Министрлык” дип исемләнә, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Әхмәтов Марат Готыф улы исеменнән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре” № 316 карары белән расланган Нигезләмә нигезендә гамәл кылучы, бер яктан, һәм

_______________________________________________________________,
(субсидия алучының аталышы, ИНН)

алга таба “Алучы” дип исемләнә, _____________________________ исеменнән,
(Ф.И.А.)

_____________________________________нигезендә гамәл кылучы, икенче яктан, икесе бергә “Тарафлар” дип аталучылар, 2015 елның 14 декабрендәге “2016 елга федераль бюджет турында” № 359-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге № 717 карары белән расланган 2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продуктларының, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 08 апрелендәге № 235 карары белән расланган “2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продуктларының, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыкларын үстерү буенча икътисади әһәмиятле булган тобәк программаларына теләктәшлек күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында” № 1042 карары (алга таба – Кагыйдәләр), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016

елның 14 мартындагы “2016 елда агросәнәгать комплексына дәүләтнең ярдәм чаралары турында” № 138 карары нигезендә түбәндәгеләр хакында әлеге Килешүне (алга таба – Килешү) төзеде:

## 1. Килешү предметы

1.1. Министрлык әлеге Килешү һәм Министрлык боерыгы нигезендә расланган Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә чучкаларның африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә объектларны чучкачылык хуҗалыкларының биологик иминлеген тәэмин итү буенча әзерләүгә; йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чараларны, йогышсызландыра торган җайланма, чучкачылык предприятиеләрендә эшләүчеләр һәм белгечләр өчен махсус кием-салым сатып алуга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга Алучыга субсидия бирү бурычын үз өстенә ала.

1.2. Килешүдә каралмаган юнәлешләр буенча чыгымнарны финанслау рөхсәт ителми.

## 2. Тарафларның хокуклары

**2.1. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:**

2.1.1. Алучыдан Килешүне үтәү өчен кирәкле булган мәгълүматны, белешмәләрне һәм документларны соратырга;

2.1.2. Законнарда билгеләнгән тәртиптә Алучы тарафыннан субсидияләр бирелүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерергә.

**2.2. Алучы түбәндәгеләргә хокуклы:**

2.2.1. Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәмен алырга. Субсидияләр законнарда билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары кысаларында бирелә;

2.2.2. Консультатив һәм мәгълүмати ярдәм алуга.

## 3. Тарафларның бурычлары

Министрлык белән Алучы әлеге Килешүнең тулы күләмдә үтәлешенә ярдәм итү бурычын үз өсләренә ала, Килешүне үтәүгә комачаулык итә торган хәлләр барлыкка килгән очракта, тарафлар бер-берсенә бу хакта хәбәр итешеп торачак һәм аны үтәү буенча килештерелгән гамәлләр кылачак.

**3.1. Министрлык бурычлары:**

3.1.1. Законнарда билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә, билгеләнгән лимитлар кысаларында, Алучының исәп-хисап счетына субсидияләрне күчерү;

3.1.2. Алучы тарафыннан шушы Килешүдә каралган шартлар үтәлмәгәндә, аңа субсидия күчерүне туктату яки субсидияләрнең зурлыгын (күләмен) киметү (кыскарту).

3.1.3. Алучы тарафыннан субсидияләрне алу өчен тапшырылган документларны тикшерү.

3.1.4. Алучыны Килешү буенча Алучының бурычларын үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.1.5. Алучы тарафыннан законнарда субсидияләрне бирү өчен билгеләнгән шартлар бозылганда, алынган субсидияләрнең законнарда билгеләнгән тәртиптә кайтарып бирелүен таләп итү.

**3.2. Алучының бурычлары:**

3.2.1. Законнарда билгеләнгән вакытта, тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән, субсидияләрне алу өчен Министрлыкка документлар җыелмасын тапшыру.

3.2.2. Министрлыкка язмача рәвештә түбәндәгеләр хакында хәбәр итү:

Алучының бетерелүе яки үзгәртеп корылуы турында, - карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көненнән артык булмаган чорда;

2002 елның 26 октябрендәге “Бөлгенлек (банкротлык) турында” № 127-ФЗ Федераль законда каралган бөлгенлек турындагы эштә кулланыла торган процедуралар кертелү хакында, - арбитраж суды тарафыннан билгеләмә чыгарылган датадан соң өч эш көненнән артмаган чорда.

3.2.3. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан Алучының субсидияләрдән максатчан файдалану кагыйдәләрен үтәвен тикшерүгә ризалык бирү.

## 4. Суммаларны кайтарып бирү тәртибе

4.1. Башкарма хакимият органнары яки бүтән вәкаләтле дәүләт контрольлек һәм күзәтчелек органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерү барышында һәм тиешле Тәртип (кагыйдәләр) һәм әлеге Килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирелү максатлары һәм шартлары бозылу очраклары ачыкланганда яки субсидияләрне алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар, хисаплар тапшырылганда, Алучы бирелгән субсидияләрне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетлары керемәнә, Алучының үзе тарафыннан әлеге очрак ачыклану датасыннан соң яки Министрлыктан акча чараларын кайтарып бирү таләбе алынган көннән соң алтмыш көнлек чорда кайтарып бирергә бурычлы.

4.2. Аталган акчаларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетлары керемәнә ирекле кайтарып бирүдән баш тарткан очракта, алар мәҗбүри тәртиптә законнар нигезендә түләттерелергә тиешле була.

4.3. Тарафларның уртак килешүе буенча һәм Алучы тарафыннан субсидияләр кайтарып бирелгән очракта Килешү ирекле нигездә тарткатыла.

## 5. Тарафларның җаваплылыгы

5.1. Бирелгән лимитларның чикләрендә субсидияләрне максатчан һәм үз вакытында күчерү өчен Министрлык җаваплы була.

5.2. Субсидияләрдән нәтиҗәле файдалану, Министрлыкка тапшырыла торган документларның, белешмәләрнең һәм хисапларның дөреслеге, тулылыгы һәм үз вакытында тапшырылуы өчен, шулай ук шушы Килешүдә һәм законнарда билгеләнгән шартларның үтәлеше өчен Алучы җаваплы була.

5.3. Субсидияләрне бирү һәм бүлү тәртипләре нигезендә Алучы кредитлардан максатчан файдаланган өчен җаваплы була. Үтәлмәгәндә Алучы бирелгән субсидияләрне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетлары кеременә әлеге очрак ачыклану датасыннан соң яки Министрлыктан акча чараларын кайтарып бирү таләбе алынган көннән соң алтмыш көнлек чорда кайтарып бирергә бурычлы.

5.4. Шушы Килешү буенча үзенең бурычлары үтәлмәгәндә яисә тиешенчә үтәлмәгәндә, Тарафлар законнар һәм шушы Килешү шартлары нигезендә җаваплы булалар.

5.5. Форс-мажор хәлләре барлыкка килгәндә, законнарда Килешү йөкләмәләрен үтәү өчен каршылык тудыра торган тыюлы яки чикләмәле чаралар кертелгәндә, Тарафлар Килешүне үтәмәгән өчен җаваплы булудан азат ителә. Югарыда саналган хәлләр барлыкка килгәндә, Тарафлар сөйләшүләр алып бара һәм Шартнамә шартларына үзгәрешләр кертә.

## 6. Бәхәсләрне хәл итү

6.1. Шушы Килешүдән барлыкка килә торган бәхәсләрне һәм ризасызлыкларны хәл итү буенча Тарафлар сөйләшүләр алып бару юлы белән барлык чараларны да күрәләр.

6.2. Килешүдән барлыкка килә торган Тарафларның барлык бәхәсләре һәм ризасызлыклары, әгәр дә сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителмәсә, законнарда билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелергә тиеш.

## 7. Бүтән шартлар

7.1. Бу Килешүгә карата барлык үзгәрешләр, өстәмәләр һәм кушымталар язмача рәвештә өстәмә Килешү белән рәсмиләштерелә һәм һәр Тарафның шуңа вәкаләт бирелгән затлары тарафыннан имзалана, ул аның аерылгысыз өлеше булып тора.

7.2. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелде, һәркайсы тигез юридик көчкә ия, Тарафларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә.

7.3. Әлеге Килешү Тарафларның һәркайсыннан шуңа вәкаләтләнгән затлар имза салгач һәм агымдагы финанс елы тәмамланганчыга кадәр гамәлдә була.

**8. Тарафларның урнашкан урыннары (дәүләт теркәвенә алынган) адреслары һәм реквизитлары:**

| | |
|---|---|
| Министрлык: | Алучы: |
| Татарстан Республикасының | ________________________ |
| Авыл хуҗалыгы һәм | ________________________ |
| азык-төлек министрлыгы | ________________________ |
| | |
| 420014, Россия, Татарстан | Урнашкан урыны: |
| Республикасы, Казан ш., | ________________________ |
| Федосеевская ур., 36 й. | ________________________ |
| | |
| р/сч:40101810800000010001 | ИНН__________________ |
| ОТДЕЛЕНИЕ-НБ | р/сч |
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ________________________ |
| г. КАЗАНЬ | ________________________ |
| | (банк аталышы) |
| УФК по Республике Татарстан | БИК___________________ |
| (Министерство сельского хозяйства | к/с______________________ |
| и продовольствия Республики | |
| Татарстан, 04112001090) | |
| ИНН 1654019555 | |
| КПП 165501001 | |
| ОГРН 1021602854580 | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасының
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министры

__________________М.Г. Әхмәтов

__________ __________________
(имза) (Ф.И.А.)
булган очракта
мөһер

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 10. 02 № 11/2-пр
боерыгына 4 кушымта
Үрнәк

________________________________________________ буенча
(субсидия алучының аталышы, муниципаль район аталышы)

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә
чучкаларның африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” тобәк
программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар
җитештерүчеләренә федераль бюджет акчалары хисабыннан тиешле
субсидияләр турында белешмә-исәпләмә

| Программаны үти башлаганнан бирле чыгымнарның бер өлешен каплауга башкарылган чыгымнар күләме | Чыгымнарның суммасы, сумнарда | Субсидия ставкасы | Субсидияләрнең суммасы, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Объектларны чучкачылык хуҗалыкларының биологик иминлеген тээмин итүгә әзерләү | | Башкарылган эшләр күләменнән 17 процент | |
| Сатып алынган йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чаралар, йогышсызландыра торган җайланма, чучкачылык предприятиеләрендә эшләүчеләр һәм белгечләр өчен сатып алынган кием-салым | | Сатып алынган йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чаралар, йогышсызландыра торган җайланма, чучкачылык предприятиеләрендә эшләүчеләр һәм белгечләр өчен сатып алынган кием-салым бәясеннән 17 процент | |
| Җәмгысе | | X | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе ________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(булган очракта) ________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасының
______________муниципаль районы

башкарма комитетының төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалык бүлеге башлыгы ________ ________________

(имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының
_______________муниципаль районындагы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе
башлыгы ________ ________________

(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(булган очракта) ________ ________________

(имза) (Ф.И.А.)

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык төлек
министры ______________________М.Г. Әхмәтов

(мөһер) (имза)

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 10. 02. №11/2-14
боерыгына 5 кушымта
Үрнәк

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2016-2018 елларга Татарстан Республикасы территориясенә
чучкаларның африка чумасы кертүне һәм таратуны туктату” төбәк
программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар
җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары
хисабыннан тиешле субсидияләр турында белешмә-исәпләмә

| Программаны үти башлаганнан бирле чыгымнарның бер өлешен каплауга башкарылган чыгымнар күләме | Чыгымнарның суммасы, сумнарда | Субсидия ставкасы | Субсидияләрнең суммасы, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Объектларны чучкачылык хуҗалыкларыныц биологик иминлеген тәэмин итүгә әзерләү | | Башкарылган эшләр күләменнән 6 процент | |
| Сатып алынган йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чаралар, йогышсызландыра торган җайланма, чучкачылык предприятиеләрендә эшләүчеләр һәм белгечләр өчен сатып алынган кием-салым | | Сатып алынган йогышсызландыра торган, акарицидлы, дератизацияли торган чаралар, йогышсызландыра торган җайланма, чучкачылык предприятиеләрендә эшләүчеләр һәм белгечләр өчен сатып алынган кием-салым бәясеннән 6 процент | |
| Җәмгысе | | X | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе _________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(булган очракта) _________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасының
_____________муниципаль районы
башкарма комитетының төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалык бүлеге башлыгы _________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының
________________муниципаль районындагы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе
башлыгы ________ __________________
(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(булган очракта) _________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык төлек
министры ___________________________М.Г. Әхмәтов
(мөһер) (имза)